Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

27 март 2020 ел № 438

Әлмәт шәһәренең Лермонтов урамыда
берьяклы хәрәкәтне оештыру турында

Юл хәрәкәтен оештыруны камилләштерү, юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 01 апреленнән Әлмәт шәһәренең Лермонтов урамы буенча автомобиль транспортының берьяклы хәрәкәтен Маяковский урамы ягына таба Радищев урамыннан Маяковский урамына кадәр оештырырга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалык департаменты» муниципаль автоном учреждениесе (Сөләйманов Җ.Ә.) күрсәтелгән урамның участогында юл хәрәкәтен җайга сала торган тиешле юл билгеләрен билгеләргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә (Зарипова Л.Н.) Әлмәт шәһәренең Лермонтов урамы буенча берьяклы хәрәкәт оештырылачагы турында халыкка хәбәр итәргә.

4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.


5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «27» март № 438
карары белән расланган
1 нче кушымта

Әлмәт шәһәренең Лермонтов урамыда берьяклы хәрәкәтне оештыру схемасы




Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары

Д. В. Косарев